| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Мунайкинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеев муниципаль районы<br>Монай авыл жирлеге Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 14 декабреннән №16

Монай авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән, Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Менделеевск муниципаль районының 2017 елның 4 сентябрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1 бүлекнең 3 пунктның 4 пунктчасындагы «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

2) 8.1 пунктның 4 пунктчасын "(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Монай авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.М.Кириллов